СОВЕТ ИШКЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Школьная, д.18, с. Ишкеево,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422161

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИШКИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Мәктәп ур., 18 нче йорт, Ишки авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422161

тел.(факс): (85563) 2-41-19; e-mail: Ishk..Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

**Решение** **Карар**

20 февраль 2023 ел. № 3-21

ТР Мамадыш муниципаль районы Ишки авыл җирлеге Советының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында

Муниципаль хокукый актлар системасын актуальләштерү максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Ишки авыл җирлеге Советы муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Ишки авыл җирлеге Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Түбәндәге карарларны үз көчен югалтты дип танырга:

- Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Ишки авыл җирлеге Советының 2005 елның 12 ноябрендәге «Җир налогы турында» 2-2 номерлы карары;

- Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Ишки авыл җирлеге Советының 2006 елның 1 августындагы «Ишки авыл җирлегендә муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләп торуга конкурс турында» 6-11 номерлы карары.

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районының mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының (pravo.tatarstan.ru) рәсми порталында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мамадыш муниципаль районының Ишки авыл җирлеге башлыгы Р.К.Хафизовка йөкләргә.

Мамадыш муниципаль районы

Ишки авыл җирлеге

Советы рәисе, җирлек башлыгы /Р.К.Хафизов/